РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА**

**Кирельского сельского поселения**

***Камско-Устьинского***

**муниципального района**

Улица Гагарина, дом №1, Камско-Устьинского района,
422827, Республика Татарстан
Телефон 8 (277) -367-45.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

***Кама Тамагы***

**муниципаль районы**

**БАШЛЫГЫ**

**Кирельского сельского поселения**

Гагарина Ур, Кама-Тамагы район, 422827,
Республика Татарстан
Телефон 8 (277)- 367-45.

# КАРАР

**2020 елның 10 ноябре** **№2**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлегенең Ишем авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлегенең Ишем авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2020 елның 27 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

« Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлегенең Ишем авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- авыл эчендәге һәм урам ара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү, вак таш сатып алу, кайтарту , вак таш җәю, тигезләү);

- җәйге-көзге чорда чүп үләннәрне чаптыру (килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

- кышкы юлларны тәртиптә тоту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары алу)

«РИЗА »                                   «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Мордва Каратай авылы, Үзәк ур., 10 йорт, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында, кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Кирельский
авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы                Ф.Я. Зиннәтуллин